КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 декабрь г.Казань № 1199

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен раслау турында

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү
тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибе (алга таба – Тәртип, бер тапкыр пособие) мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белемнең белем бирү оешмасын тәмамлаган елда белем алу турында һәм (яки) квалификация хакында документта күрсәтелгән бирелгән квалификация нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына эшкә кергән 30 яшькәчә яшь белгечләргә (алга таба – яшь белгеч) бер тапкыр пособиеләр бирү механизмын, күләмен һәм тәрибен билгели.

## 2. Бер тапкыр пособие түләү өчен нигезләр

2.1. Бер тапкыр пособие яшь белгечләргә бер тапкыр түбәндәге нигезләрне үтәгәндә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бирелә:

2.1.1. Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белемнең белем бирү оешмасын тәмамлаган елда белем алу турында һәм (яки) квалификация хакында документта күрсәтелгән бирелгән квалификация нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына эшкә керү (төп эш урыны буенча).

2.1.2. Яшь белгеч эшли торган Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында урнашкан.

2.1.3. Белем алу турында һәм (яки) квалификация хакында документта күрсәтелгән бирелгән квалификация нигезендә мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү программалары буенча һөнәри белем турында дәүләт үрнәгендәге документ булу.

2.2. Бер тапкыр пособие алу өчен Министрлык, яшь белгеч эшли торган оешма

һәм яшь белгеч арасында өчьяклы килешү булырга тиеш, анда яшь белгечнең мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасында (алга таба – оешма) кимендә өч ел эшләү йөкләмәсе күрсәтелә.

2.3. Министрлык бер тапкыр пособие билгеләнгән яшь белгечләр реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыра һәм алып бара. Реестрны формалаштыру һәм алып бару тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

2.4. Яшь белгечнең Тәртипнең 2.1 пункты таләпләренә туры килмәве һәм Тәртипнең 4.1.1, 4.1.2 пунктларында каралган документларны Министрлыкка тапшырмау бер тапкыр пособие түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

## 3. Бер тапкыр пособие күләме

3.1. Бер тапкыр пособие күләме тәшкил итә:

һөнәри белем бирү оешмасын тәмамлаган һәм авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасының дәүләт яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына эшкә кабул ителгән яшь белгечләргә 50 000 сум;

югары белемнең белем бирү оешмасын тәмамлаган һәм авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасының дәүләт яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына эшкә кабул ителгән яшь белгечләргә100 000 сум.

## 4. Документлар бирү тәртибе

4.1. Бер тапкыр пособие алу өчен яшь белгечләр Министрлыкка агымдагы елның 25 декабренә кадәр (25 декабрьне кертеп) түбәндәге документларны тапшыра:

4.1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы раслаган форма буенча бер тапкыр пособие бирү турында гариза.

4.1.2. Оешма җитәкчесе таныклаган күчермәләре:

белем алу турында һәм (яки) бирелгән квалификациясе белән квалификация хакында документ;

эшкә алу турында боерык;

хезмәт килешүе;

хезмәт кенәгәсе;

паспорт (барлык тутырылган битләр) шәхесне таныклаучы бүтән документлар;

салым органында исәпкә кую турында таныклык;

мәҗбүри пенсия иминиятләве иминиятләү таныклыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы раслаган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык;

яшь белгеч эшли торган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасы турында әлеге оешма җитәкчесе имза куйган белешмә, оешманың рәсми исемен күрсәтеп (ИНН, ОГРН, ОКВЭД).

## 5. Бер тапкыр пособие бирү турында гаризаларны карап тикшерү тәртибе һәм бер тапкыр пособие бирү хакында яки бер тапкыр пособие бирүдән баш тарту турында карар кабул итү

5.1. Гариза һәм Тәртипнең 4 бүлегендә күрсәтелгән теркәлә торган документларны яшь белгеч Министрлыкка тапшыра, ул гариза һәм теркәлә торган документлар кергән көннән соң 10 эш көне эчендә аларны карап тикшерүне гамәлгә ашыра һәм яшь белгечкә бер тапкыр пособие бирү хакында яки бер тапкыр пособиене бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

5.2. Яшь белгечкә бер тапкыр пособие бирү хакында яки бер тапкыр пособиене бирүдән баш тарту турында карар Министрлык тарафыннан боерык формасында кабул ителә.

5.3. Бер тапкыр пособие бирү хакында яки бер тапкыр пособиене бирүдән баш тарту турында Министрлык боерыгы басылып чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә яшь белгечкә бер тапкыр пособие билгеләү хакында яки бер тапкыр пособиене бирүдән баш тарту турында язма формада хәбәрнамә җибәрә.

5.4. Министрлыкның яшь белгечкә бер тапкыр пособие түләү турында карары кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Министрлык бер тапкыр пособие бирү турында өчьяклы килешү төзи. Өчьяклы килешү формасы Министрлык боерыгы белән раслана.

## 6. Бер тапкыр пособие күчерү һәм кире кайтару тәртибе

6.1. Бер тапкыр пособие бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюдже ассигнованиеләре һәм Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

6.2. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш идарә итүче булып тора һәм Министрлыкның яшь белгечкә бер тапкыр пособие түләү турында боерыгы чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә акча чарасын үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган исәп-хисап счетыннан бер тапкыр пособие алучыларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

6.3. Тәртипнең 4.1.2, 4.1.4 пунктларында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен оешма җитәкчеләре җавап тота.

6.4. Яшь белгеч белән хезмәт килешүе туктатылган очракта оешма бу хакта язма рәвештә азат итү нигезләрен күрсәтеп, өч эш көне эчендә Министрлыкка хәбәр итә.

6.5. Яшь белгеч оешма белән төзегән килешү өч ел узганга кадәр туктатылган очракта яшь белгеч бер тапкыр түләүнең күрсәтелгән вакыт узганга кадәр калган көннәрдә эшләнмәгән вакытка пропорциональ билгеләнгән бер өлешен Татарстан Республикасы бюджетына Министрлыкның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган исәп-хисап счетына Россия Федерациясе Хезмәт

кодексының 80 статьясы, 81 статьясындагы 3, 5, 6, 8, 11 пунктлар, 83 статьясындагы 4 һәм 8 пунктлар, 336 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларда каралган нигезләр буенча хезмәт килешүе туктатылган көннән башлап 30 көн эчендә кире кайтарырга тиеш.

6.6. Яшь белгеч Тәртипнең 6.5 пункты таләпләрен ирекле рәвештә үтәмәгән очракта Министрлык бер тапкыр пособиене кире кайтару вакыты узганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына алу чараларын күрә.

6.7. Хезмәт килешүе Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы 5 пунктында каралган нигезләр буенча туктатылган очракта (хезмәткәрне аның соравы яки аның ризалыгы белән башка эш бирүчегә эшкә күчергәндә) һәм Татарстан Республикасының башка муниципаль районына дәүләт яки муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасына эшкә күчкәндә әлеге Тәртипнең 3 бүлегендә күрсәтегән бер тапкыр пособие күләме, әгәр хезмәткәр оешма белән хезмәт хокук мөнәсәбәтләрен күрсәтелгән вакыт эчендә дәвам итсә, хезмәткәр тарафыннан кире кайтарылмый.